**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 7 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- ул халык авыз иҗатының иң кыска жанры;
- ул күчерелмә мәгънәле афористик гыйбарә, хикмәтле сүз дигәнне аңлата;
- сүзне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру вазифасын үти.

**Җавап:** Әйтем

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

ә) сатира, юмор, афоризм, сарказм


б) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, бәет

**Җавап:** ә) сатира, юмор, афоризм, сарказм

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**


**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**


1) 2) 3)





а) ә) б)





**Җавап:** 1) ә; 2) а; 3) б.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Һади Такташ «Мокамай»

Әмирхан Еники «Матурлык»

Габдулла Тукай «Исемдә калганнар»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Хәлвәфрүш а) «Онытылмас еллар»

2) Әхмәдулла ә) «Туган ягым – яшел бишек»

3) Хәлим б) «Кәҗүл читек»

4) Гомәр в) «Әбугалисина»

**Җавап:** 1) в; 2) б); 3) а; 4) ә.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы — моңлы җырчы –
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.

Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңә
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә, эше калсын
Мең яшәрлек имән булып.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)_________**

**б) Имән агачын кем утырткан? Ул нинди кеше? (3 балл) ____________**

_______________________________________________________________________

**в) Кеше белән имән охшашылыгы нәрсәдә чагылыш таба? (3 балл) _____**

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

**г) Шигырьнең төп фикере кайсы юлларда бирелә? Шул юлларны табып языгыз. Сез бу фикер белән килешәсезме? Фикерегезне тормыштан мисаллар белән раслагыз (4 балл) ___________________________________**

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Имән

ә) Муса Җәлил

б) Бер кеше утырткан. Ул тырыш, ярдәмчел, киң күңелле, эшчән кеше һ.б.

в) Кеше белән имәннең охшашлыгы аларның башка кешеләргә карата игелек кылуларында чагылыш таба.

г) Төп фикер соңгы юлларда бирелә: Җирдә кеше торса торсын, эзе калсын тирән булып, үзе үлсә, эше калсын, мең яшәрлек имән булып. Бу фикер белән килешәм. Кеше һәрвакытта да игелекле, яхшы гамәлләр генә кылып, шул эшләре өчен рәхмәт әйткәнне көтмичә яшәргә тиеш. Үзе бу дөньядан киткәннән соң да исеме яхшылык белән телгә алынып халык хәтерендә сакланырга тиеш.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл)**

*Милли, мәйдан, сабан эшләре, бәйрәм рухы, матур киенгән, күңелле, шат, ярышлар, батыр, чүлмәк, гармун тавышы.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы**
**8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- Шәрык әдәбиятында һәм фольклорында лирик жанр атамасы, дини эчтәлекле әсәр;
- ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ярлыкау;
- ул гадәттә көй белән башкарыла.

**Җавап:** мөнәҗәт

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, бәет

ә) драма, комедия, трагедия, трагикомедия


б) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, популяр җырлар, кыска җырлар

**Җавап:** б) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, популяр җырлар, кыска җырлар


**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**


1) 2) 3)







а) ә) б)







**Җавап:** 1) ә; 2) а; 3) б.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Һади Такташ «Мокамай»

Әмирхан Еники «Кем җырлады»

Мөхәммәт Мәһдиев «Без – кырык беренче ел балалары»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

4. **Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Хәлим а) «Кем җырлады»

2) Гомәр ә) «Туган ягым – яшел бишек»

3) Әлтәфи б) «Онытылмас еллар»

4) Таһирә в) «Без – кырык беренче ел балалары»

**Җавап:** 1) б; 2) ә); 3) в; 4) а.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман-кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.

Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә лирик герой нинди хисләр кичерә? (4 балл)**

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**в) Әсәрдә сугыш чынбарлыгын сурәтләүдә кайсы табигать образлары ярдәмгә килә? Аларны языгыз (2 балл)**_________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

________________________________________________________________

**г) Фашизм нәрсә ул? Ни өчен аның яшәргә хакы юк? Лирик геройның фашизмга мөнәсәбәтен билгеләгез. Сез бу фикер белән килешәсезме? Фикерләреңне нигезләгез (3 балл)** ___________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Бездә – яздыр

ә) Фатих Кәрим

б) Лирик герой соклану, тынычлану, сагыну хисләре кичерә.

в) Кошсыз урман-кырлар, сынып беткән, изрәп тапталган урман, кеше каны белән тапланган чәчәкләр, төтен белән капланган язгы таң нуры.

б) Лирик геройның фашизмга мөнәсәбәте катгый. Фашизм – ул иң кешелексез, иң ерткыч, кансыз күренеш. Фашизм аркасында күпме кеше һәлак булган, җәзаланган, газап кичергән. Шуңа күрә дә аның киләчәге дә, яшәргә хакы да юк.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Өмә, күмәк, күңелле, бергәләп, җырлый-җырлый, күңел ачу, эш-хезмәт, уңган, яшьләр, оештыру, көлешү, шат тавышлар, ярдәм итү, булышу.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- матур яңгырашлы, аһәңле, затлы сүз дигәнне аңлата;
- ул кемнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны данлау, киләчәк буыннар хәтеренә, халык күңеленә язып шул тарихта калдыру дигән сүз;
- бу жанрда иҗат ителгән әсәрләрнең күпчелеге үзәгендә алып-батыр яки пәһлеван образы тора.

**Җавап:** дастан

**2. Хаталбелән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) тарихи җыр, газәл, дастан, мөнәҗәт

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, җырлар, кыска җырлар



б) драма, комедия, трагедия, трагикомедия

**Җавап:** а) тарихи җыр, газәл, дастан, мөнәҗәт



**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)

а) ә) б)

**Җавап:** 1) ә; 2) б; 3) а.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Габдулла Тукай «Пар ат»

Шәйхи Маннур «Муса»

Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

| | |
|---|---|
| 1) Исмәгыйль | а) «Сөйләнелмәгән хикәя» |
| 2) Биктимер | ә) «Галиябану» |
| 3) Закир | б) «Буранда» |
| 4) Мостафа | в) «Алмачуар» |

**Җавап:** 1) ә; 2) а); 3) в; 4) б.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

Мин монда хокуклы. Тукталып,
Чакырсам, әгәр дә ым кагып,
Рухыма тиң булып, рухыма, –
Яныма басачак мең Алып.
... Моң салып нәселем үткән бит,
Кодрәтем биредә күптән бит:
Сак басам түмгәкләр өстенә,
Аягым корымас микән, дип.

Биредә күлләрем – көзгеләр,
Көзгеләр һәрберсе – изгеләр...
Кыл дога һәм күзәт үзеңне, –
Күлләр дә болгана, түзмиләр.

Күкрәктә тыпырдый кош, дулап,
Очыртсам – барасы юл ерак...
Ак кошым, пакь кошым, очма син,

Йөрик бер Ватанда, төш юрап.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьдә нинди ил турында сүз бара? (2 балл)**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**в) Шигырьдәге теманы ачарга кайсы образлар ярдәм итә? Аларның мәгънәләрен аңлатып языгыз (4 балл)_________________________________**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләгез (3 балл) __________________________________________________**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Каеннар илендә

ә) Мөдәррис Әгъләмов

б) Шигырьдә туган ил, Ватан, Болгар иле турында сүз бара

в) Каеннар иле – туган ил, мең Алып – Ватанның батырлары, түмгәк – тарихтагы канлы вакыйгалар, күл-көзге – тарих, Ак кош – ирек.

г) Кеше туган илен, Ватанын яратырга, сакларга, аның тарихын белергә, аның белән горурланырга тиеш.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Аулак өй, кичен, җеп эрләү, бәйләү, чигү, сөлге, бирнә, кызлар, егетләр, гармун, күңелле, җыр-бию, уен-көлке, шат тавышлар.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**

**1. Әдәбияттагы нинди юнәлеш турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- аның асылын Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган тәгълимат тәшкил итә;
- аның тарафдарларын башка төрле итеп «диндар», «дәрвиш», «тәкъва», «акыл иясе» дип йөрткәннәр;
- әдәбияттагы әлеге күренеш мөселман кешесенең үз-үзен, рухын камилләштерү юлы белән Аллага якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле системадагы дини-фәлсәфи, мистик карашлар һәм йолалар җыелмасыннан гыйбарәт.

**Җавап:** суфичылык әдәбияты

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар


б) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, нәсер


**Җавап:** а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)







а) ә) б)







**Җавап:** 1) ә; 2) б; 3) а.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»

Габдрахман Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»

Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»

**ә) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Мансур — а) «Әйтелмәгән васыять»

2) Суфиян — ә) «Галиябану»

3) Исмәгыйль — б) «Кыйссаи Йосыф»

4) Йагъкуб — в) «Ак чәчәкләр»

**Җавап:** 1) в; 2) а); 3) ә; 4) б.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә (исенә төшерә) ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**___________

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**__________

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә нәрсә күренеше бирелә? (3 балл)**___________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

**в) Ана теләгенең көчен шигырьдә кайсы детальләр белдерә, шуларны язып чыгыгыз (3 балл)**_____________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл)** ______________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Ана догасы

ә) Габдулла Тукай

б) Шигырьнең беренче өлешендә төнге авыл күренеше бирелә.

в) Догага күтәрелгән куллар, улына Ходайдан бәхет сорау, тамчы-тамчы күз яшьләре.

г) Барлык аналар үз балаларына яхшылык, балаларының бәхетле булуын тели.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Кәләш, кияү, йола, туй, никах, мәҗлес, ак бөркәнчек, бал-май, хөрмәт итү, мәхәббәт хисе, бәхет теләү, әти-әни, туганнар.*

**Иншгызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 11 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**.

**1. Кайсы иҗат методы турында сүз баруын язагыз (2 балл):**

- ул татар әдәбиятында XIX гасырның икенче яртысында формалаша;
- аның тарафдарлары әдәбиятка тормышның актуаль проблемалары хакында уйлану мөмкинлеге итеп карыйлар;
- сурәтләү объекты итеп, тиз үзгәрүче дөньядагы эшлекле кеше сайлана; сюжет билгеле бер карашны расларлык яки кагарлык итеп корыла; кешене аң-белемгә өндәү, югары идеалларга хезмәт итәргә чакырыла; кеше табигатьтә яши дип, табигыйлык тәрбияләү шарты куела, кешегә тирәлекнең уңай һәм тискәре йогынтысы ассызыклана.

**Җавап:** мәгърифәтчелек реализмы

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) хикәя, повесть, роман, новелла

ә)  дастан, бәет, мәдхия, мөнәҗәт

б) мәрсия, мәсәл, робагый, газәл

**Җавап:** ә)  дастан, бәет, мәдхия, мөнәҗәт


**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)

а) ә) б)

**Җавап:** 1) б; 2) ә; 3) а.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**Җавап:**

Габдрахман Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»

Гадел Кутуй «Тапшырылмаган хатлар»

Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Искәндәр а) «Кыйссаи Йосыф»

2) Ягъкуб ә) «Тапшырылмаган хатлар»

3) Мәхмүт б) «Сүнгән йолдызлар»

4) Сәрвәр в) «Мәхәббәт тәүбәсе»

**Җавап:** 1) ә; 2) а); 3) в; 4) б.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, —
Парә-парә (телем-телем) кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, — әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак (бары тик) мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! —
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхрары мәхәббәт (мәхәббәт утында янган) миннән уңда, зан итәм (уйлыйм), —
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин аларның таңчысы!

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә рус һәм чит әдәбиятларының кайсы күренекле вәкилләре искә алына? (3 балл)**______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**в) Лирик герой нинди хисләр кичерә? Ни сәбәпле? Шулар турында языгыз (3 балл)**____________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл)** ___________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Мәхәббәт

ә) Габдулла Тукай

б) Байрон, Лермонтов, Пушкинны искә төшерә

в) Ярату, гыйшык хисе – кызга гашыйк булу, мәхәббәт ләззәтеннән газаплану – яшерен мәхәббәт, соклану хисе – матурлыкка соклану.

г) Матурлык алдында баш ию Җир кешеләрен мәхәббәт патшалыгына илтә һәм алар өчен бетмәс-төкәнмәс иҗади илһам орлыкларын чәчә.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Аулак өй, кичен, җеп эрләү, бәйләү, чигү, сөлге, бирнә, кызлар, егетләр, гармун, күңелле, җыр-бию, уен-көлке, шат тавышлар.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы irekle.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

**.**